РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
ТОЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул.Джалиля , д.19, с.Тойкино,
Азнакаевский район, 423302

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТУЙКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Җәлил ур., 19 нче йорт, Туйкә авылы,
Азнакай районы, 423302

Тел./факс(885592)-45089; E-mail: Toy.Azn@tatar.ru,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08 ноябрь 2019 ел № 37

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Кымшлы Күл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 21 ноябрь 2019 ел 17 сәг.00 минутта Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Камышлы-Күл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.1. Билгеләргә:

-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Камышлы – Күл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Башкарма комитеты;

-гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 21 ноябрь 2019 ел 17.00 сәг.тән 18.00 сәг.кадәр;

-үткәрү урыны – Камышлы Күл авылы, Ленин ур., 11Б й., Камышлы Күл авылы мәчет бинасы;

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түйкә авылы, Җәлил урамы,19 йорт;

- сайлау хокукына ия булган Камышлы Күл торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Камышлы Күл торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Түйкә авыл җирлеге Камышлы Күл торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 500 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Камышлы Кул авылы, Ленин урамы буенча юлларга вак таш (щебенка) җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, эшләр өчен килешү буенча түләү);
- Камышлы Күл авылында Ленин урамы исеме белән күрсәткечләр сатып алу;
- Камышлы Күл авылында юлларны кардан чистарту;
- үзәкләштерелгән чыганаклардан эчә торган суны анализлау: «Салкын Чишмә» чишмәсе;
- Камышлы Күл авылында «Авыл бәйрәме»н үткәрү өчен бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, хезмәт күрсәтү;
- Камышлы Күл авылы Ленин урамы юлының техник паспортын ясату;
- Камышлы Күл авылы зиратынын җир кишәрлеген ызанлау;

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, һәм түбәндәге адреслар җуенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Җәлили ур.,19 йорт;
ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы Гагарин ур., 4а йорт;
ТР, Азнакай муниципаль районы, Камышлы-Күл, Ленин ур., тукталыш янында;
ТР, Азнакай муниципаль районы, Карамалы-Елга ур., Сәйдәшев ур., № 19а йорт янында;

5. Әлеге карар ул игълан ителгән көннән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык Р.Р.Закирова